# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 5 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында" 1992 елның 19 февралендәге 1448 – XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы өченче өлешен (2003 елның 23 сентябрендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 4, № 9-10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 9; 2003, № 9 (II өлеш); 2005, № 12 (I өлеш); 2006, № 3 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ай календаре һәм урнашкан традицияләр нигезендә Корбан бәйрәме башлануга туры килә торган көн Татарстан Республикасы Президенты указы белән эш көне булмаган бәйрәм көне дип игълан ителә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2007 елның 19 апреле

№ 13-ТРЗ